ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Суыксу авыл җирлегенең
Ташсу авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

08 декабрь 2021ел №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 04 декабрендә 11 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. " 2022 елда балигъ булган һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы? Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүчеләрдән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

а) Бөек Ватан сугышы катнашучыларына һәйкәлне күчерүгә;
б) Рөхсәтсез чүплекне бетерүгә ;
в) Тракторга өстәмә җиһазлар алуга.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 83 (сиксән өч) катнашучы кертелгән, 44 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:
халык җыенында 44 (кырык дүрт) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Ташсу авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. 2022 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Ташсу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) Бөек Ватан сугышы катнашучыларына һәйкәлне күчерүгә;
б) Рөхсәтсез чүплекне бетерүгә ;
в) Тракторга өстәмә җиһазлар алуга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.С.Низамиев